# АВЫЛЫМНЫҢ ТАРИХЫ

# (ЯХШЫБАЙ)

14.02.2004 г.

Яхшыбай авылының Мәсгүт авылыннан күчеп килү чоры. 1921 – елда Яхшыбай авылына кучәргә теләүчеләрнең исемлеген төзеп, һәр кемгә (шабага салып) үзенә тигән урынга казык кагып чыгалар. Ул җир 040 с/х чамасы җир була. 1921 елда корылык килеп иген уңмый, каты ачлык була. Кешеләр ул елны поселыкка күчә алмыйлар. Только авылның югары очына Гайфуллин Сәетгәрәй, түбән очына Рахимов Ахунҗан килеп кышны берсе бер очта, икенчесе икенче очта кышлап чыгалар. 1922 – елда инде башка кешеләр дә күчеп бетәләр

Авылда кешеләрнең утыру, урнашу тәртибе мондый була:

*Су буйлап, урман яклап, түбән очтан:*

1. Шарапов Салах
2. Низамов Зиннур
3. Заһртдинов Мөхәммәди
4. Рахимов Ахунҗан
5. Сөләйманов Юсуф

***Тыкырык***

6. Нигмәтуллин Шафыйк
7. Кәсимов Хафиз
8. Котлыйов Барый
9. Мулла йорты Хәниф мулла
10. Кәримов Сафа

***Тыкырык***

11. Хөсәинов Фәхрислам (мөәзин)
12. Усманов Корбан
13. Алмакаев Фаттах
14. Низамов Хәертдин
15. Сәлимәнов Рәхимҗан

***Тыкырык***

16.Баһауов Авзал

17.Гайфуллин Сәетгәрәй

18.Гайфуллин Вәлиулла

19.Низамов Мифтах

20.Кәримов Гариф

Тыкырык урнына Мухамметов Миннәхмәт.

***Башкача, төбән очтан күл яклап:***

1. Зиннуров Усман
2. Фәтхуллин Әһели
3. Кашапов Мохәммәтҗан
4. Зиннуров Гөмәр
5. Гәбитов Халиулла

***Тыкырык***

6. Бәдертдинов Гыймади
7. Кәримов Гәлим
8. Саттаров Сабир
9. Идрисов Иблиәмин
10. ................ Насыйбулла

***Тыкырык***

11. ................ Садыртдин
12. Фатхуллин Гиният
13. Хисамов Мөхәммәт
14. Хисамов Йосып
15. Усманов Миннегол

16. ............... Кәрим
17. Хәлиуллин Гатаулла
18. Мифтахов Фәрди
19. Мөстәкимова Зифа
20. Рахимов Габдулла

Урам уртасына матур итеп мәчет салалар, шуның өчен авыл уртасындагы 3 хуҗалык Фахерислам, Корбан, Фаттахлар өйләрен урамнан эчкә салалар, мәчет очен урын калдырып. Мәчет булгач мулла кирәк була. Камы-Елга авылыннан Хәниф мулланы авылга йорт салып (мулла өчен) күчереп алып киләләр.

Авылга исем кушу кала. Берәүләре авыл исемен су буе бөтенләй зирек булмаганга Зирекле-елга булсын дип, икенчеләре су буенда карама агачы күп булганга Карамалы-елга өченчеләре имеш суында керкә балыгы күп булганга Керкәле-елга кушыйк диләр. Шуннан мулла кеше:

– “Җәмәгәт, авылның урыны бик яхшы минемчә, яхшы да булсын, байда булсын” – ди.

Шулай итеп авылга Яхшыбай исеме бирәләр.

Яхшыбай шулай матур гына баеп ятканда 1928 елда җәй көне пожар чыгып авыл уртасыннан, Хөсәинов Фахирисламнан Кәримов Гарифка кәдәр 2 тыкырык арасы янып көлгә әйләнә. Инде янган хуҗалыклар яңадан йорт, җир тергезеп тернәкләп башлагач кына 1930 елда колхоз оештыра башлыйлар, ул озак яши алмый тарала. .

1931 елда яңадан ныклап колхоз оештыралар. Кешеләрнең ничә аты булса шуны, 2 сыеры булса берсен, үзендә булган ат сбруй арба-чана, келәте булганнарның келәтен алып колхозга берләштерделәр. Инде бу ихтияри түгел,

мәҗбүри талап алу иде.

Колхозга кермәгән кешеләрнең барлык малларын талап алып үзләрен өйләреннән куып чыгарып, авылдагы бердән бер сушилка, Рәхимҗан сушилкасын яптылар да күтәрә алмастай акчалата налог салдылар, түзәлмәгәч алар да колхозга гариза биреп керделәр. Ул еллар мәхшәр иде диләр.

Сушилкага ябылучылардан:

1. Усманов Корбан, 4 баласы белән
2. Хөсәенов Фахрислам мөәзин иде, 5 баласы белән
3. Низамов Хәертдин, 4 баласы белән
4. Усманов Миннегол, 7 баласы белән
5. Фатхуллин Гиният, 2 баласы белән

Алар шул күтәрә алмаслык налог түләп аргач, гариза язып колхозга кергәч үз өйләренә кайтырга ризалык бирделәр. Шулай итеп колхозлашып, колхозга исемне "НУР" дип кушалар, председательләре булып берсен берсе алыштырып түбәндәге кешеләр эшли:

1. Габитов Халиулла (Яхшыбай);
2. Зиннуров Гомәр (Яхшыбай);
3. Кашапов Гата (Сарлы);
4. Шәмсетдинов .......... (Урсай);
5. Галиев Мөхәмәт (Мәсгут); һәм башкалар.

1932 елда тыныч кына эшләп, яшәп ятканда авылда тагын пожар чыгып Бәдертдинов Гымадидан Насибуллага кәдар бер тыкырык арасы янып бетә. Авылга 1932 елда беренче трактор кайта, беренче мәртәбә авыл халкының трактор курүе була. Олысы кечесе трактор күрергә йөгерешәләр. Колхозда эшләгән эшкә түләү тәртибе хезмәт көне бирәмлеге була. Мәсәлән: һәр бер төрле, эшкә норма куела, норманы тутырып эшләсә 1 көн, я булмаса 1,5 хезмәт көне языла. Норма мисал өчен сабан сөрү – 1га тырма тырмау 4 гектар (ат белән); чалгы белән печән чабу норма – 80 сотых; шушылай ел буена,

бер кешҫ яхшыгына эшләсә 300-400 хезмәт көне эшли. Көз көне уңышны җыйнап алгач, хөкүмәт заданияләрен тутырып сименага, фуражга аерып салып куйгач күпме кала, шул икмәкне колхозчыга бүлеп бирәләр иде. Ул кайбер елны хезмәт көненә бирергә бер грамм да калмый иде. Иген унган елны бик куп тә була иде. Безнең авылның җирләре яхшы иде, икмәк һәр елны яхшы булды, колхоз районда һәр вакыт яхшылар рәтендә йөрде, шулай да 1932-1936 елларда гомуми районда ачлык булды, 1937 елда уңыш чамасыз уңды. Безнең колхоз хезмәт көненә 8-әр кило ашлык оләште кешеләр икмәк салырга урын юк дип барып алмагач, атка төяп, алып килеп ишек төбенә аударып китуләре дә булды. Шулай яхшы гына эшләп баеп ятканда гына, 1941 елда 22 июнь район сабантуе көнне Бөек Ватан сугышы башланды. Авылдагы сугышка яраклы барлык ир-затын сугышка кан-яшь түгеп озаттык. Колхоз эше бер-ничә карт-корыга, хатын-кызга, бала чагага калды. Сугыш башланасы елда колхоз председателе Рахимов Габдулла була ул колхозны Рахимов Ахунҗанга тапшырып узе сугышка китә.

***Ватан сугышына китүчеләрнең исемлеге:***

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Мухамметов Миннәхмәт | Исән кайтты |
| 2. | Гарипов Шәмсемхәммәт | Үлде |
| 3. | Гарипов Фатых | Исән кайтты |
| 4. | Низамов Ваһап | Исән кайтты |
| 5. | Саетов Миниегәрәй | Үлде |
| 6. | Саетов Харис | Исән кайтты |
| 7. | Бахауов Афзал | Исән кайтты |
| 8. | Авзалов Зиятдин | Исән кайтты |
| 9. | Авзалов Әсгат | Исән кайтты |
| 10. | Рахимов Мөхәммәтҗан | Исән кайтты |
| 11. | Усманов Тимергали | Үлде |
| 12. | Усманов Нургали | Исән кайтты |

| | | |
|---|---|---|
| 13. | Хөсәенов Әзһәт | Исән кайтты |
| 14. | Фатхуллин Мотыйгулла | Исән кайтты |
| 15. | Алмакаев Зәкәр | Исән кайтты |
| 16. | Исрафилов Вагиз | Исән кайтты |
| 17. | Хафизов Барый | Үлде |
| 18. | Хафизов Фатих | Исән кайтты |
| 19. | Рахимов Мхәмәт | Үлде |
| 20. | Загртдинов Шәйхеразый | Үлде |
| 21. | Бәдериев Миргасим | Исән кайтты |
| 22. | Шарапов Сәләх | Исән кайтты |
| 23. | Нуриев Нурлегади | Үлде |
| 24. | Зиннуров Усман | Үлде |
| 25. | Зиннуров Нургали | Үлде |
| 26. | Гаттаров Мостафа | Үлде |
| 27. | Сәетов Асылгәрәй | Үлде |
| 28 | Зиннуров Рәис | Үлде |
| 29. | Габитов Шәмгун | Үлде |
| 30. | Халиуллин Шамиль | Үлде |
| 31. | Бәдртдинов Гыймади | Исән кайтты |
| 32. | Зиннуров Гариф | Исән кайтты |
| 33. | Гатауллин Вадигулла | Үлде |
| 34. | Садриев Насырый | Үлде |
| 35. | Садриев Заһертдин | Үлде |
| 36. | Саттаров Харрис | Үлде |
| 37. | Мухамметов Фоат | Үлде |
| 38. | Усманов Камиль | Исән кайтты |
| 39. | Каримов Хажи | Үлде |
| 40. | Гатауллин Муса | Исән кайтты |
| 41. | Гатауллин Закуан | Исән кайтты |

| | | |
|---|---|---|
| 42. | Рахимов Габдулла | Исән кайтты |
| 43. | Низамов Фәрди | Үлде |

Бөек Ватан сугышына Яхшыбай авылыннан барысы 43 кеше китеп, шуның 22-се исән кайтты (гәрип гораба булса да), 21-се сугыш кырында үлеп калды. Сугыштан соң тагын ачлык, ялангачлык башланды, дәвам итте. 1947 елда соңгы солдатлар кайтып бетте. Инде ничек яшәү кайгысы гына калды. Хөкүмәттә колхозларны эреләндерү политикасы туды, шул исәптән безнең "НУР" колхозын 1950 елда Мәсгут колхозына кушып "МОЛОТОВ" дип исем бирделәр. Колхозның председателе итеп Әлкәй авылы кешесе Хаҗиахметов Шәрипне куйдылар.

Сталин үлгәч культ-личностька бәйләп колхоз исемен 1954 елда "МОЛОТОВ" исемен алмаштырып "ОКТЯБРНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫ" куштылар. 1965 елда колхозда эшләүче кешегә: хатын-кыз 55 яшькә, ир ат 60 яшькә җиткәч пенсия бирү башланды. 1962 елда авылга электр уты керде. 1990 елда авыл урамына таш җәйделәр. 1997 елның язында колхоз Мәсгүттән аерылып, Яхшыбай колхозы булып, председателе Низамов Фазыл булды, шул елны урамга асфальт җәйделәр. 1999 язында Фазыл урнына Зарипов Наил дигән Карамалы кешесен куйдылар. Ул кеше колхозны 2-3 елда тәмам эштән чыгарып, 2002 елның язында тагын Мәсгут колхозына куштылар – председателе Имамов Басыйр.